МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№________________

На №________________от________________

Rossiya Federaciyase töbäkläreneñ
mägarif idaräläre çitäkçelärenä

Tatarstan Respublikasi
Rossiya Federaciyase təbäkläre, yakin
häm erak çit il väkillläreneñ çitäkçelärenä

Tatar milli-mädäni möhtäriyatläre,
tatar içtimagyj oeşmalari çitäkchelärenä

Tatar telennän VII Halikara
olimpiada ütkärü turinda

Tatarstan Respublikasy Mägarif häm fän ministrligi (alga taba – Ministrlik) Tatarstan Respublikasi, Rossiya Federaciyase subektlari häm çit illärdä yaşäüçe ukuçilar häm studentlar öçen tatar telennän VII Halikara olimpiada (alga taba – Olimpiada) ütkärelüe turinda häbär itä,

Olimpiadada 8-11 sijnif ukuçilari häm Tatarstan Respublikasi, Rossiya Federaciyase subektlari häm çit illärdäge yugari häm urta hönäri belem birü oeşmalari studentlari katnaşa.

Çit illärdäge yugari häm urta hönäri belem birü oeşmalari studentlari, məktäplärdä belem aluçi 8-11 nçe sijnif ukuçilary öçen Olimpiada tübändägeçä başkarila:

1. KFU portalinda (abiturient.kpfu.ru) terkälü;
2. KFU portalinda (abiturient.kpfu.ru) tatar tele häm ädäbiyatinnan biremnärne distant ytäü;
3. Tatar telennän Internet-test nätiçäläre buença distancion ängämädä katnaşu;
4. Iñ yugari ball çiyuçi balalarniñ Olimpiadaniñ jomgaklau etabinda katnaşui.

KFU portalinda (abiturient.kpfu.ru) terkälü 2018 nçe elniñ 15 nçe noyabrennän 10 nchi dekabrenä kadär ütkärelä.

Internet-test ütkärü distant räveştä üzläreneñ komp'yuterlarinda 2018 nçe elniñ 12-27 nçe dekabrenä kadär ütkärelä.

Internet-testta katnaşu öçen KFU portalinda (abiturient.kpfu.ru) terkälü mäçbüri.

Olimpiadaniñ jomgaklau etabinda katnaşuçilarniñ isemlege 2019 nçi elniñ 1 nçe martina kadär KFU portalinda (abiturient.kpfu.ru) häm Ministrlik sajtinda (http://mon.tatarstan.ru) urnaştirilaçak.

Olimpiadaniñ jomgaklau etabi 2019 nçi elniñ aprelendä Kazan şähärendä ütkärelä.

Olimpiadaniñ jomgaklau etabi ike turda ütä:

1. Tatar tele, ädäbiyat häm Tatarstan tarihi buença yazma eş.
2. «Dön'ya kiñlegendä Tatarstan» temasi buença proekt eşlären yaklau.

Oeştiru komiteti: 8(843) 294-95-89, 294-95-71, 294-95-09, 2949510, Guliya.Musina@tatar.ru

Tekhnik yardäm kürsätü buença: 8(843) 2387711; e-mail: rt.test@kpfu.ru